ЭШКӘ БИРСӘҢ...
Республиканың мәгълүмати куркынычсызлыгына җәлеп ителгән инвестицияләр үзен аклый
> 2

СӨЕНЕРЛЕК НӘТИҖӘ
11 нче сыйныф укучылары БДИда соңгы сынауны узды
> 2

ТУГАН ТУФРАК
Белоруссиядә җирләнгән герой каберенә Татарстаннан бер уч туфрак салдылар
> 3

ГАРМУНЧЫ КАДЕРЕ
Актанышта гармун уйнап урам әйләнүне кире кайтармакчылар
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 87 (29054) | Чәршәмбе | 21 июнь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ТАТАР БАЛАСЫНА КАЯ БАРАСЫ?

РЕСПУБЛИКАДА ТАТАР ТЕЛЛЕ БЕЛГЕЧЛӘРНЕ КАЙЛАРДА ӘЗЕРЛИЛӘР?

Кичә Россиянең барлык югары уку йортларында кабул итү комиссияләре эшли башлады. Мәктәп бусагасыннан атлап чыгып, студент булырга әзерләнүчеләрнең иң дулкынландыргыч көннәре җитте. Татарстанда татар телле белгечләрне кайларда әзерлиләр? Бюджет урыннары күпме? Без әнә шуларны белештек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Хәзер инде кая барырга да белмим...»

Соңгы арада татар журналистларын, төгәлрәк әйткәндә, татар журналисты булырга хыялланучыларны борчу басты. Сер түгел, матбугатчыларның да күпчелеге киләчәк турында уйланырга мәҗбүр булды. Сәбәбе – быел КФУның Социаль фәлсәфә фәннәре һәм массакүләм коммуникацияләр институтының Журналистика һәм медиакоммуникацияләр югары мәктәбендә татар журналистлары өчен бюджет урыннарының бөтенләй (!) булмавы. Милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы мөдире Васил Гарифуллин сүзләренчә, быел читтән торып укучылар өчен генә 20 бюджет урыны каралган, көндезге уку бүлегенә керәм дисәң, елына 155 мең сум түлисе булачак. Кыскасы, татар журналисты булам дисәң, кесәң күңелең кебек киң булсын. «Магистратурада көндезге бүлектә – 10, читтән торып уку бүлегенә 5 бюджет урыны бар», – диде безгә Васил Гарифуллин.

Сүз уңаеннан, узган ел хәлләр күпкә яхшырак иде. 2022 елда татар журналистикасы (Яңа милли медиа чаралары) бүлегенә җиде бюджет урыны бүлеп бирелгән иде. Берсе дә буш калмады – җиде булачак журналист мәш килеп укып ята. Читтән торып уку бүлегендә дә бер студент бар. 11нче сыйныфны тәмамлаган Зилә Хәбибуллина да нәкъ менә шушы бүлеккә укырга керергә теләгән. «Шаян ТВ» балалар телеканалында эшләүче кыз, ничек кенә булса да, киләчәген журналистика белән бәйләргә тели.

– Татар журналистикасында бюджет бүлегенә студентлар җыймаячакларын БДИлар башланганчы ук белдем. Башта бик аптырадык инде. Минем көн саен дәресләргә йөреп, төркемдәшләрем белән очрашып, кыскасы, нәкъ менә көндезге уку бүлегендә укыйсым килгән иде. Хәзер инде күңелем тынычланды. Шушы ук бүлектә читтән торып уку юнәлешен карыйбыз. Алай да була бит. Эшләргә, тагын да күбрәк проектларга алынырга мөмкинлегем булачак. Иң мөһиме – кабул итсеннәр, – диде ул безгә. – Күпләр югары уку йорты сайлауны киләчәк тормышны сайлау дип кабул итә. Мин моның белән килешмим. Уку йортын сайлауга җиңелрәк карыйм.

Нурлат районының Колбай-Мораса мәктәбен тәмамлаучы Әлфинә Хисамова да татар журналисты булырга хыяллана. «Бюджет урыннары юк икән шул. Хәзер инде кая барырга да белмим», – диде булачак студент. Сүз уңаеннан, Әлфинә – татар теленнән бердәм республика имтиханын тапшырган сигез укучының берсе.

Бер җирдә ишекләр ябылса...

...икенче җирдә, киресенчә, яңадан ачыла әнә. Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетында быел билингваль төркем җыячаклар. Университетның мәгариф эшчәнлеге буенча проректоры Илфак Вилданов сүзләренчә, ике телле белгечләр әзерләү бүген аеруча актуаль.

– Ике телдә – татар һәм рус телләрендә укытачакбыз. 20ләп урын бар. Абитуриентларны районнардан максатчан уку (целевой. – **Авт.**) программасы буенча кабул итәргә җыенабыз, – дип аңлатты ул. – Университетта татар төркемен заманында татар мәктәпләреннән килгән балаларга русча уку авыр булгач ачкан идек. БДИны рус телендә тапшыргач, хәзерге татар балаларына русча уку бер дә авыр түгел. Шулай да, ике телле белгеч көндәшләреннән бер баш өстен була. Бүген бу аеруча актуаль. Мондый төркемдә укуның зур өстенлеге әнә шул инде.

Җитәрме, юкмы?

Татарстанда татар телле белгечләрне әзерли торган төп уку йорты – КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты. Габдулла Тукай исемендәге милли мәдәният һәм мәгариф Югары мәктәбе деканы Рамил Мирзаһитов әйтүенчә, быел, нәкъ узган елгы кебек үк, ике төркем җыячаклар.

– Беренче төркем – татар теле, әдәбияты һәм инглиз теле укытучылары. Алар өчен 25 бюджет урыны бар. Филологлар әзерли торган, ягъни татар теле, әдәбияты һәм журналистика бүлегендә 20 бюджет урыны каралган. Болар – бакалаврлар өчен. Магистрлар өчен 13 бюджет урыны бар, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Моннан тыш, рус, татар һәм инглиз телләрен белүче полилингваль белгечләр әзерли торган биш төркем җыячаклар. Барысы бергә 125 кеше өчен урын бар. «Студентларны максатчан уку буенча кабул итәчәкбез. Алар ай саен 15 мең сум стипендия алып укыячак», – диде Рамил Мирзаһитов.

Балтач районының Куныр мәктәбен тәмамлаучы Зилия Юнысова нәкъ менә шушы институтка укырга кереп, татар теле укытучысы булырга хыяллана. «Татар теленнән БРИны да махсус шуның өчен сайладым», – диде ул.

Моннан тыш, татар телле белгечләрне КФУның Алабуга институтында да әзерлиләр. Инглиз теле, туган (татар) тел һәм әдәбият бүлегендә быел 20 бюджет урыны бар. Чаллы дәүләт педагогика университетында да филология факультетының рус теле, туган (татар) тел һәм әдәбият бүлегендә 15 бюджет урыны әзерләп куйганнар.

Сан

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы хәбәр итүенчә, 2023–2024 уку елына республика югары уку йортларында барлыгы 21102 бюджет урыны бүлеп бирелгән.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Арттырырга исәп

2025 елга Казанның авиация заводы елына ун Ту-214 очкычы чыгара башлаячак. Бу хакта «ТАСС» агентлыгы вәкиле белән әңгәмәсендә Берләшкән авиатөзелеш корпорациясе җитәкчесе Юрий Слюсарь хәбәр иткән. Аның сүзләреннән аңлашылганча, алга таба заводта елына егерме очкыч төзергә җыеналар. «Казан авиазаводы техник яктан тулысынча җиһазландырылачак», – дип белдергән Юрий Слюсарь.

Заводта елына ун, аннары егерме очкыч җитештерелә башлаячагын моңа кадәр Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та хәбәр иткән иде. Моның өчен заводның станоклар паркын яңартырга, яңа җиһазлар сатып алып алырга җыеналар.

Бер елда – дүрт мәктәп

Быел Казанда дүрт мәктәп ачылачак. Анда алты меңнән артык укучы белем алачак. Шәһәр мэры Илсур Метшин әйтүенчә, шәһәр өчен рекордлы күрсәткеч бу.

«Казанның яңа тарихында беренче тапкыр шәһәрнең төрле районнарында алты мең балага дүрт яңа мәктәп төзибез. Бу – рекорд. Моны күптән көттек. Әлеге мәктәпләрдә балаларыбызга белем алу өчен генә түгел, үз сәләтләрен үстерү өчен дә бөтен шартлар булачак. Биредә искиткеч концерт заллары, бассейн, спорт мәйданчыклары, җиһазландырылган физика, химия кабинетлары ачылачак. Яңа микрорайоннар өчен аларның янәшәдә генә урнашуы аеруча мөһим», – диде Илсур Метшин яңа төзелүче мәктәпләрнең берсендә оештырылган күчмә утырышта.

Аларның берсе Совет районында Курынов урамында төзелә. Бина 70 процентка әзер. 184 нче мәктәпнең өстәмә корпусы 1501 урынга исәпләнгән. Аны «Мәгариф» илкүләм проекты кысасында төзиләр. Мәктәп территориясендә футбол, баскетбол белән шөгыльләнү өчен мәйданчыклар, йөгерү юллары булачак. Быел сафка басачак дүрт мәктәпнең өчесе Раис Гәрәев һәм Нигъмәтуллин урамнарында, «Салават Күпере» микрорайонында төзелә.

«Ефәк юлы» башлана

5 июль көнне Казанда «Ефәк юлы» халыкара ярышы старт ала. Ралли-рейдта катнашучылар илнең 13 төбәге аша узачак. Маршрут озынлыгы – 5421 чакрым. Халыкара ярыш Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Республика Хөкүмәте ярдәмендә уза.

Ярышны ачу тантанасы Меңьеллык мәйданында узачак. Кунакларны җырлы-биюле программа, мотоцикл, квадроцикллар тамашасы көтә. Катнашучылар 7 категориядә ярышачак. Узышның беренче көне 7 июльгә билгеләнгән. Беренче этапның махсус участогы Татарстан аша уза. 142 чакрымлы участок Лаеш районының Державино бистәсе янында башланып, Мамадыш районының Катмыш авылы янында төгәлләнә. Ралли 15 июльгә кадәр дәвам итәчәк. Финиш – Мәскәүдә. Сүз уңаеннан, Чаллының «КАМАЗ-Мастер» командасы әлеге узышта 5 экипаж белән чыгыш ясый.

kamazmaster.ru

Чаң!

Чишенә урман

Татарстанда агачларның яфрагын корт ашый. Әлеге хәбәр күпләрне пошаманга салды. Республиканың төрле районнарында яшәүчеләр, яфраксыз агачларга тап булып, бу хакта социаль челтәрләрдә яза башладылар.

«ВТ» редакциясенә Нурлат районының Чулпан авылында яшәүчеләр дә шалтыратты.

– Әни белән урманга барсак, яфраксыз агачлар күреп шаккаттык. Агачны кортлар сырып алган, – ди үзен Ләйсәния дип таныштырган ханым.

Чирмешән районының Иске Кади авылында яшәүче блогер Равил Закиров та урманда агачларның шәрә калуы турында сөйләде. «Туксан яшьлек әбинең дә мондый хәлне күргәне булмаган», – дип язган ул.

Нурлат урманчылыгы җитәкчесе Рөстәм Галиев фикеренчә, агачларны ефәк корты (шелкопряд) ашый.

– Һәр нәрсәнең тәртибе булган кебек, кортка агу сибүнең дә үз кагыйдәләре бар. Без агачларны агуладык. Әмма бу эшләрне корт зарарлаган агачлык авылдан, елгалардан, умарта ояларыннан 3 чакрым ераклыкта булса гына башкарып була. СанПиН таләбе шундый. Шуңа кайбер урыннарда кортлар калды. Еш кына авыл халкы да бер фикергә килә алмый. Кайберәүләр, агулагыз, дисә, кайсылары, тимәгез, ди. Корт агуының зыяны юк түгел. Шундук сиздерә, – ди ул.

Чирмешән урманчылыгы җитәкчесе Алмаз Мотыйгуллин сүзләренчә, алар узган ел ук ефәк кортына тап булганнар. Нурлат районы белән чиктәш урында 65 гектар җирдә кортлар агачларга зыян салган була. Кыштан соң кортлар бетәр дип өметләнәләр. Тик алай булып чыкмый. Ефәк корты быел 20 мең гектар мәйдандагы урманга зыян сала.

– Безнең урманнарга ефәк корты 10 ел саен һөҗүм итә инде ул. Аннан котылуның бер генә ысулы бар – агулау. Без бөтен җирне биологик препарат белән эшкәрттек. Әлеге урманнарда комиссия эшли. Препаратның нәтиҗәлелеген тикшерә. Корттан зыян күргән агачлар исә киләсе елга яфрак ярачак. Без химик препарат белән агулау яклы түгел. Ул бөтен экологик системага зыян сала. Шуңа күрә башка юллар эзлибез. Киләсе елда да шушы хәл кабатланса, агуны өстән, вертолет ярдәмендә сиптермичә булмас, – ди ул.

Кортлардан аеруча Алексеевск районындагы Биләр җирлеге зыян күрде. Биләр урман хуҗалыгы җитәкчесе Рамил Нуруллин белән дә элемтәгә кердек.

– Әлеге кортлар безгә Нурлат якларыннан килеп үрчеде. Узган ел бу хакта аңлатканнар иде. Кышкы салкыннарда исән калмаслар дип уйлаган идек, башкача килеп чыкты, – ди ул. – Урман хуҗалыгында 40 ел эшлим. Мондый хәлне беренче күрүем. Юкса, ефәк корты курчагы күбәләккә әйләнеп, очып китәргә тиеш. Болар ашыкмый әле, һаман ашыйлар.

Рамил Нуруллин да, кортлар агачка зыян салмый, дип ышандыра.

– Күпләр әлеге кортларның зыян салуын климатка бәйли. Әмма мин килешмим. Монда бар да экологиягә бәйле дип уйлыйм. Ник дигәндә, авыл хуҗалыгында эшләүчеләр эшләрен җайга салды хәзер. Ашлыкны киптереп тә маташмыйлар, гербицид сибәләр дә ул коп-коры тора. Җирне эшкәртү өчен күпме агу сибелә. Җитештерүчеләр елга биш мәртәбә басуларын агулый. Без үзебез дә сизмәстән табигатьнең экологик системасына зыян салабыз. Чебенне дә агулыйбыз, черки дә ошамый. Кирәкле бөҗәкләр үлеп бетә, кирәксезе кала. Менә бу кортларны агулаудан да кошларга зыян килмәсме? – ди ул.

Ахыры 3 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Тамара ФРОЛОВА,
Дәүләт Думасы депутаты:

Донорлар өчен түләүне арттырырга кирәк. Хәзерге вакытта әлеге түләүләр яшәү минимумының 5 процентын тәшкил итә. Россиядә донорлык системасын популярлаштырырга кирәк. Без ил куркынычсызлыгы, кешеләрнең гомер озынлыгы һәм сәламәтлеген саклау турында сөйлибез. Донор каны яраланган хәрбиләргә һәм тыныч халыкка да һәрдаим кирәк.

(«Аргументы и факты»)

РОССИЯДӘ – ФӘКЫЙРЬЛЕК ДӘРӘҖӘСЕ

2022 елда илдә 14,3 миллион, ягъни халыкның 9,8 проценты фәкыйрьлек чигеннән түбәнрәк дәрәҗәдә яшәгән. РИА «Новости» мәгълүматларына караганда, бу – узган елгыдан 1,2 процентка азрак. Чагыштыру өчен: 2012 елда әлеге күрсәткеч – 10,7, ә 2000 елда 29 процент булган.

ИҢ ТҮБӘН ҺӘМ ИҢ ЮГАРЫ КҮРСӘТКЕЧЛЕ ТӨБӘКЛӘР

	Төбәк	Фәкыйрьлек дәрәҗәсе, %	Үзгәреш
1	ЯНАО	4,5	-0,1
2	Санкт-Петербург	4,5	-0,5
3	Мәскәү	5,0	-0,5
4	**Татарстан**	**5,0**	**-1,2**
5...	Мәскәү өлкәсе	5,5	-0,5
...81	Алтай Республикасы	20,4	-2,0
82	Калмыкия	21,0	-1,6
83	Карачай-Черкес	22,0	-0,1

Ярдәм вәгъдә итәләр

Татарстанда психик тайпылышлары булган кешеләргә ярдәм итүне күздә тоткан тәҗрибә проекты эшли башлаячак. 2026 елга кадәр исәпләнгән әлеге проект республиканың Мәшгульлек үзәкләре белән бергә гамәлгә ашырылачак.

Белгечләр психик тайпылышы булган кешеләргә эшкә урнашканда дөрес итеп резюме тутырырга өйрәтәчәкләр, документлар җыйганда, килешү төзегәндә дә ярдәм итәчәкләр. Эшкә урнашкач та, алар ике ай дәвамында күзәтү астында булачак. Әлеге проектта катнашу өчен, кеше социаль ярдәмгә мохтаҗ дип танылган булырга тиеш. Медицина ягыннан да каршылыклар булмау шарт. Төгәлрәк әйтсәк, җитди психик чирләре, венерик, хроник тире авырулары булган, эпилепсиянең катлаулы формасы, туберкулез, ВИЧ аркасында килеп чыккан авырулардан интеккән кешеләр әлеге проектта катнаша алмаячак.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

СӨЙЛӘШҮ ҺӘМ ЧЫНБАРЛЫК

Дүшәмбедә мәгълүмат кыры Блинкенның Кытайга визиты турында яңалыклар белән тулды. Сәяси күзәтүчеләр «АКШның дәүләт секретарен (тышкы эшләр министры дип аңлыйк) Си Цзиньпин кабул итәрме-юкмы?» дигән сорауга җавап эзләде.

Кызык инде: ике державаның мөһим сөйләшүләре нинди югарылыкта барачагы соңгы минутка кадәр билгесез калды. «Российская газета»ның «Телеграм» каналы Си – Блинкен очрашуы булмаячак дип хәбәр итәргә дә өлгерде. Әмма очрашу булды барыбер. Бары тик 45 минут кала гына чин лидерының Американың югары дипломатын кабул итәчәген әйттеләр. Сөйләшү 35 минут кына барды. Соңыннан Си: «Кытай һәм АКШ Блинкенның Пекинга визиты вакытында күп кенә мәсьәләләр буенча килешүгә һәм прогресска ирештеләр. Бу бик яхшы», – дип белдерде.

Блинкен да берничә мөһим белдерү ясады: АКШ Тайваньның бәйсезлеген яклавчы һәм Кытай белән конфликтка керергә нияте юк, Вашингтон Кытайдагы системаны алыштырырга да, аның белән «салкын» сугышка керергә дә омтылмый. Си да Кытайның АКШ мәнфәгатьләрен хөрмәт итүен белдерде.

Бик мөһим белдерүләр инде уйлап карасаң. Әмма меморандумнар белән тормыш чынбарлыгы соңгы елларда бер-берсенә һич кенә дә туры килми. Шулай да күзәтүчеләр АКШ – Кытай мөнәсәбәтләре 2022 елның февраленә кадәрге дәрәҗәдә торгызылды дип саныйлар. Сөйләшүнең төп темалары, әлбәттә, пәрдә артында калдырыла, мәгълүмат кырына аларның сөземтәсе генә чыгарыла. Россиягә кагылышлы мөһим белдерүләр яңгырамады. Әмма дүшәмбе кичендә НАТО генераль секретаре Столтенберг Россия белән Кытай бер якта сугышка торган хәрби конфликтны бик җиңел күз алдына китереп булуын әйтте.

Зур державалар үзара мөнәсәбәтләрне ачыклаганда, Фәләстыйн – Израиль каршылыгы янә канлы бәрелешкә әверелде. Канкоеш алдыннан Болонья – Тель-Авив маршруты буенча очучы ирланд авиакомпаниясенең Ryanair очкычы бортында җәнҗал купты. Стюардесса берничә тапкыр рейсның соңгыноктасы оккупацияләнгән Фәләстыйн булуын игълан иткән. Пассажирлар (аңлашыла инде, аларның күпчелеге – гыйбриләр) ярсып, стюардессаны сүзләрен төзәтергә чакыргач, и тегесе баш тарткан. Европалылар арасында хакыйкатьне тануны дан курыкмаучылар барлыгын дәлилли ул факт.

Фәләстыйндагы дүшәмбе канкоешы иса бу юлы Газзәдә түгел, Җенин (русча Дженин) шәһәрендә оештырылды. Җенин Иордан елгасының Көнбатыш ярында урнашкан, соңгы 22 елда анда зур бәрелешләр булганы юк иде. Дүшәмбедә исә Җенингә вертолетлардан ракета һөҗүмнәре ясадылар, калканлы техника белән һөҗүм иттеләр. Израиль снайперлары журналистларга ата дигән хәбәрләр дә килде. Халыкара мәгълүмат кырына бәрелеш шуңа күрәдерме аз яктыртылды. Сугыш барышында Израильнең байтак хәрби техникасы юк ителде, солдатлары яраланды. Фәләстыйнлылар ягында да җәрәхәт алучылар күп. Автор Җәниндәге «Әбү Сина» хастаханәсенең кан белән юылган идәнен төшергән видеороликлар алды. Дүшәмбедә ун сәгать барган бәрелештән соң Израиль солдатлары чигенде. Конфликт яңа югарылыкка чыгарыла.

Россиядә

АЛАЙ ГЫНА БУЛМЫЙ УЛ

Бу көннәрдә, ягъни 19–23 июньдә Парижда акча «юдыру»га каршы көрәш чаралары эшләүче дәүләтара төркемнең (Financial Action Task Force, FATF) пленар утырышы бара. Утырышның төп темасы – Россияне FATF исемлегенә кертү. Бу исемлеккә әләгү дәүләткә әстәмә кыенлыклар тудыра: илнең барлык банклары да халыкара түләүләр системасы SWIFTтан өзелә, тышкы сәүдә кыенлаштырыла, чит илгә акча күчерү бөтенләй диярлек мөмкин булмый башлый. Дөрес, без болай да шул хәлдә диярлек инде. Әмма «кара исемлек»кә әләгү эшне тотальә рәвештә кыенлаштыра. Илнең идарәче элитасы вакыйгаларның андый үсешен теләми. Шуңа күрә 12 илгә (дус илләргә) FATF исемлегенә кертмәүләрен сорап мөрәҗәгать итте.

FATF – 1989 елда төзелгән структура, аңа 39 ил керә. Россиянең оешмадагы әгъзалыгы 2022 елның 24 февралендә туктатылды. «Кара исемлек»кә кертелү сумның курсына тискәре йогынты ясаячак, чит ил товарларын китерү дә кыенлашачак. Эшнең тагын бер кыен ягы бар бит әле: Төркия, Согуд Гарәбстаны, Һиндстан, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре кебек илләр дә – FATF әгъзалары. FATF исемлегенә эләксәң, ул илләр арасында да акча күчерү һәм сәүдә итү кыенлашачак. Катастрофа ук булмас, әлбәттә. Иран да – исемлектә, әмма ул яшь һәм сәүдә итә. Ләкин Иран кәгазь доллар һәм евро белән эш итә ала, ягъни валютаны капчыклап ташый. Россия өчен монысы да тыелган.

Утырышта кискен карар кабул итәлмәс, мөгаен. Нәрсә дисәң дә, халыкара базар Россия чималыннан тулысынча баш тарта алмый. Башта илне «соры» исемлеккә кертү ихтималы бар. Андый исемлектә Төркия, Сүрия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре бар инде. «Соры исемлек» хокуклары берникадәр чикли, әмма тулысынча тыймый.

Санкцияләрнең кертелгән кадәре дә эшләрне җитәрлек кыенлаштыра. Аларны әйләнеп узарга теләүче дәүләтләргә дә каттый чаралар карала. Финляндиянең яңа эшкә керешүче хөкүмәте, мәсәлән, Африканың Россияне яклаучы дәүләтләренә финанс ярдәмен туктатырга ниятли. Финнар үсеп килүче илләргә ел саен 1 миллиард евро ярдәм күрсәтә икән. Үткән елның февраленә кадәр Финляндия Россиянең иң якын дусларыннан берсе иде. Хәзер НАТО составында һәм, димәк, каршы лагерьда.

Россия бюджеты дефициты һәм кыенлыклар кичерә. Хөкүмәтнең икътисад блогы бюджет чыгымнарын «приоритетлаштыру» турында сүз күтәрә инде. Чыгымнарны тигез кисмәячәкләр, кайбер тармакларны тунап, икенчеләрен финанслауны саклаячаклар. Бездә генә түгел, санкциясез һәм нык үскән илләрдә дә хәл якынча шулай. Франция сәламәтлек саклауга чыгымнарны 10 миллиард евроя киметтә, мәсәлән. Шулай булгач, бездә бюджетның киселүе һәм бәяләрнең күтәрелүе гаҗәп түгел.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ЭШКӘ БИРСӘҢ ЧЫН КҮҢЕЛ

25 килешү, «KazanForum» тәҗрибәсе һәм илкүләм рейтингта – икенче урын. Татарстан Хөкүмәт йортында Төньяк башкалада узган Петербург халыкара икътисадый форумы нәтиҗәләре турында сөйләделәр.

tatarstan.ru

Билгеле булганча, җыен эшендә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендә йөзгә якын кешедән торган республика делегациясе дә катнашты. 1997 елдан бирле, пандемия чорыннан кала, ел саен үткәрелүче форум быел технологик суверенитетка багышланган иде. Татарстан кунаклары йортучесез «КамАЗ», инновациялә эшләнмәләр, Россия компьютерлары һәм ноутбуклары белән шаккатырды. Мәсәлән, республика стенды янәшәсендә кунакларны каһвә ясаучы робот-бариста каршы алды, шунда ук робот-кул белән «таш – кайчы – кәгазь» уенын уйнарга мөмкин иде. Эш арасында гына, әлбәттә.

Форум дәвамында республика делегациясе төрле оешмалар, чит ил вәкилләре һәм Россия төбәкләре белән 25 килешү төзегән. Бу хакта журналистларга Татарстан Инвестиция үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина әйтте. Санкт-Петербургтагы җыенда шәхсән катнашмавына тәртерүчеләргә дә бик тиз җавап тапты ул.

– Мондый форумнар уңышының 80 проценты әзерлеккә бәйле. Петербург халыкара икътисадый форумында ел саен катнашабыз. Быел безнең төп шигарь – «Татарстан – киләчәк инде бүген үк» дип аталды. Ул инновацияләргә бәйле иде. Җыен барышында төзелгән килешүләр саны республика делегациясенең уңышы турында сөйли.

Дөрес, Талия Миңнуллина яңа килешүләрнең бәясен әйтмәде. «Аларның барысы да акчага бәйле түгел бит», – дип кенә чикләнде ул. Инновацион үсеш агентлыгы җитәкчесе Санкт-Петербургтагы чараны күптән түгел Казанда узган икътисадый җыен белән дә чагыштырып карады.

– Бу ике икътисадый форум бервакытта да бер-берсе белән көндәшлек итмәячәк. Чөнки аларның үткәрелү вакыты һәм үзенчәлекләре төрле. Саннарга килгәндә, Казанда узган җыенда 16 меңгә якын кеше катнашса, Санкт-Петербургта – 17 мең кеше иде. Төзелгән килешүләр 130га 900не тәшкил итте. Без дөньяның 80 иленнән кунаклар кабул итсәк, Төньяк башкалага 130 илдән килделәр. Без моннан да күбрәккә дәгъва да кылмыйбыз, чөнки «KazanForum» ислам илләренә юнәлдерелгән. Быел Петербург форумында тәүге тапкыр хәләл индустрия, ислам банкингы кебек темалар күтәрелде. Бу хакта сөйләгәндә, «KazanForum» тәҗрибәсен еш телгә алдылар.

Петербург форумында илгә ислам банкингы ярдәмендә инвестицияләр җәлеп итүгә багышланган аерым чара да узган. Бу хакта Татарстан Премьер-министры урынбасары – икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов әйтте. Сөйләшү барышында быелның июлендә илдә ислам банкингына бәйле закон проекты кабул ителәчәге дә билгеле булган.

– Әлеге документта Татарстаннан барлык тәкъдимнәр дә исәпкә алынды, – диде министр.

Мидхәт Шаһиәхмәтов тагын бер сөенечле хәбәргә туктады. Россия төбәкләрендә инвестицион климат торышы илкүләм рейтингы нәтиҗәләре буенча Татарстан Мәскәүдән генә калыша. Бу хакта форум барышында билгеле булды. Исегезгә төшерәбез: илкүләм рейтинг төбәк хакимиятләренең бизнес өчен уңай шартлар тудыруын бәяли һәм моңа бәйле иң яхшы тәҗрибәләрне ачыклый. Узган ел нәтиҗәләре буенча нибары ике төбәк – Мәскәү һәм Татарстан 300 баллык чикне узып киткән. Беренче өчлеккә Мәскәү, Түбән Новгород һәм Төмән өлкәләре дә эләккән. Мидхәт Шаһиәхмәтов сүзләренә караганда, исемлеккә 67 күрсәткеч буенча төзелгәр.

– Республика – шуларның 50се буенча әйдәп баручылар арасында, – диде ул. – Без 16 баскычка югары күтәрелдек. Аерым алганда, Татарстанда төзелеш өчен рөхсәт алу, милеккә теркәү, электр челтәрләренә тоташу вакыты кимүен билгеләп үттеләр. Республикада кече һәм урта бизнеска финанс ярдәм чараларының сыйфатыннан һәм уңайлылыгыннан канәгать булучылар да арта.

Ә тырышлык беркайчан да юкка чыкмый. Монысын бу көннәрдә генә тормыш үзе раслады. Атна башында Татарстанда дәүләт оешмалары сайтлары начар эшләде. Сәбәбен брифингта әйттеләр.

– Дүшәмбе көнне республиканың мәгълүмат системасына моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә киберһөҗүм ясалды. Мондый хәлне 2022 елдан бирле белмибез. Без гадәттән тыш хәлне булдырмыйча калдык. Республиканың мәгълүмати куркынычсызлыгына җәлеп ителгән инвестицияләр үзен аклады, – диде Татарстан дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Игътибар өчен рәхмәт!

Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия» партиясенең Татарстан төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин партия Рәисе Дмитрий Медведевның Төбәк иҗтимагый кабул итү бүлмәсендә халыкны кабул итте.

Бөек Ватан сугышы ветераннары Зинаида Бушуева һәм Зәйтүнә Хөсәенова Дәүләт Советы Рәисенә «Безнең ишегалды» программасы нигезендә йорт яны территорияләрен төзекләндерү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать иттеләр. Ветераннар республика җитәкчелегенә Казан шәһәре Яңа Савин районындагы Лаврентьев урамында күптән түгел уздырылган капиталь төзекләндерү өчен рәхмәт сүзләрен җиткерде. Төзекләндерү тәмамлангач, май аенда, партиянең җирле бүлеге активистлары ветераннар өчен Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган бәйрәм оештырды. «Алар район халкы өчен бәйрәм концерты куйдылар, – дип сөйләде ветераннар, – безгә күрсәтелгән игътибар бәяләп бетергесез».

Зинаида Бушуева Ленинград блокадасын кичергән, аннары озак еллар Казанның Үзәк телеграфында эшләгән. Зәйтүнә Хөсәенова сугыш елларында оккупацияләнгән территориядә яшәгән, Таавитти концлагере тоткыны булган. Хәзер алар актив иҗтимагый эшчәнлек белән шөгыльләнәләр. Бүген иса ветераннар парламент башлыгын үзләренең төзекләндерелгән ишегалдына чакырдылар. Фәрит Мөхәммәтшин актив гражданлык позициясе өчен аларга рәхмәт белдерде һәм озын гомер теләде.

Бөгелмә районында яшәүче III төркем инвалид Илдар Әхмәткәримов белән Фәрит Мөхәммәтшин телефоннан сөйләште. Ир-атка җирле сырхауханәдә түләүле тикшеренү үтүгә генә юллама биргәннәр, ә аның инвалидлык буенча пенсиясе зур түгел. Фәрит Мөхәммәтшин бу мәсьәләне үз контроленә алды.

«Бердәм Россия» партиясе Казан җирле бүлегенең Авиатөзелеш районындагы иҗтимагый кабул итү бүлмәсе җитәкчесе Наталья Панфилова оборона предприятиеләрендә эшләүче яшьләр белән очрашу оештыруы тәкъдимен җиткерде.

БЕРТАВЫШТАН ХУПЛАНДЫ

Фәрит Мөхәммәтшин кандидатурасы Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (академигы) итеп сайлау өчен тәкъдим ителде.

Кичә Казанда Татарстан Фәннәр академиясенең социаль-икътисадый һәм гуманитар фәннәр бүлекләренең берләштерелгән отчет-сайлау җыелышы булды. Анда кайбер фәнни юнәлешләр буенча Татарстан Фәннәр академиясе хакыйкый әгъзалары (академиклары) һәм әгъза-мөхбирләре вакансияләренә сайлау өчен кандидатураларны карап тикшерделәр. «Политология» белгечлеге буенча Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы вакансиясенә сайлау өчен, Дәүләт Советы Рәисе, сәясәт фәннәре докторы Фәрит Мөхәммәтшин кандидатурасы ике бүлек әгъзалары тарафыннан да бертавыштан хупланды.

Парламент башлыгы билгеләп үткәнчә, аның хезмәт юлы озак еллар иҗтимагый-сәяси өлкәгә бәйле булган. «Узган гасырның давыллы туксанынчы елларындагы социаль-икътисадый эшчәнлек, барлык әһәмиятле мәсьәләләр буенча да җәмәгатьчелек фикерен анализлау өчен, тәҗрибәгә нигезләнгән гаять бай материал бирде, – диде ул. – Татарстанлыларның рухи халәтен даими рәвештә белешеп тору дәүләтнең «базарга йомшак керү» сәясәтен фәнни яктан нигезләргә, сәнәгать-икътисад тармагын саклап калу һәм үстерү буенча зур бурычларны хәл итәргә, республикадагы социаль процессларны тотрыклыландырырга мөмкинлек бирде. Бу темага монографияләремдә, мәкаләләр һәм чыгышларымда бәян ителгән нәтиҗәләр 1996 елда социологик фәннәр кандидаты гыйлми дәрәҗәсен алу өчен язылган диссертациямнең нигезен тәшкил итте».

Фәрит Мөхәммәтшинның фәнни эшчәнлегенең икенче юнәлеше булып федерализмны үстерү мәсьәләләре тора. Аның докторлык диссертациясе «Республиканың – РФ субъектының – социаль-сәяси үсеш факторы буларак федератив мөнәсәбәтләр» темасына язылган иде. «Татарстанда без федераль үзәк белән мөнәсәбәтләр кору принципларын еш кына интуиция нигезендә формалаштыра идек», – дип искәртте Дәүләт Советы Рәисе.

Шулай ук Фәрит Мөхәммәтшин академикларның игътибарын яңартылган дәүләтчелек төзү процессында милләтара дуслык һәм татулыкны саклап калу эшендә Татарстан җитәкчелеге кулланган ысулларның Россия күләмендә һәм халыкара танылуына юнәлтте. Бу өлкәдәге эксперт потенциалының Россия Федерация Советы, Татарстан Рәисе каршындагы консультатив органнар эшчәнлегендә файдаланылуын, фәнни докладлар, мәкаләләр язганда кулланылуын ассызыклады ул.

Утырышта «археология», «политология» белгечлекләре буенча хакыйкый әгъзалар, «җинаять-хокук фәннәре» һәм «педагогика» белгечлекләре буенча әгъза-мөхбирләр вакансияләренә кандидатуралар да карап тикшерелде.

Тәкъдим ителгән кандидатларны сайлау 23 июньдә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең гомуми җыелышында булачак.

КИЛӘ ДӘ КИТӘ

БДИ – 2023

11 нче сыйныф укучылары БДИда соңгы сынауны узды. Казанның 139 нчы мәктәбендә информатика буенча имтихан тапшыручыларга уңышлар теләргә Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин да килгән иде. Быелгы нәтиҗәләр сөенерлекме?



Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстанда информатика һәм мәгълүмат технологияләреннән БДИны барлыгы 3 мең 281 укучы тапшырды. Бу – барлык укучыларның 20 проценты дигән сүз. Узган елга караганда, 700 балага күбрәк. Димәк, әлеге сан IT юнәлешенең тормышка тагын да ныграк керүен күрсәтә. Әлеге фәннән ким дигәндә 40 балл җыярга кирәк. Узган ел республикада информатикадан уртача балл 67,91не тәшкил иткән.

Казанның 139 нчы мәктәбендә оештырылган имтихан пунктына КФУның Лобачевский исемендәге мәктәп-интернаты һәм 21 нче гимназияне тәмамлаган укучылар җыелды. Арада кызлар да бар. «Бу фән белән егетләр генә кызыксына дип әйтү дөрес түгел. Информатика бездә да кызык», – диешеп алар.

Алисә Сабирова КФУның бизнес-информатика юнәлешенә укырга кермәкче. Рус теленнән 100 балл җыйган кыз моңа ирешү авыр булмас дип өметләнә. Дөрес, үзен «акыллы баш» дип санамый. Информатикадан ким дигәндә 90 балл алырга тели. «Башка фәннәрне ныклап өйрәнсәм дә, информатикага игътибар җитмәгән иде. Биремнәр күп, аларны өйрәнергә туры килде. Онлайн мәктәптә шөгыльләндем. Аның ярдәме тиде. Имтиханнар иртәрәк дә, дуслар белән аралашырга да комачауламады. Атнага бер көн үземә ял билгеләдем», – диде ул.

Наил Бутяков та КФУның Лобачевский исемендәге мәктәп-интернатын тәмамлаган. Ул Мәскәүгә укырга барырга җыена. Сәбәбе дә бар икән. «Хәзер әти-әниләр дә башка яшисем, барысын да үзем мөстәкыйль хәл итәсем килә. Минем бернечә кумирым бар. Алар нәкъ менә Мәскәүдә танылу алган. Нигә миңа да үземне сынап карамаска?»

Имтихан бирәсе бар, дип борчылып, ашау һәм йокы турында онытмаган егет. Ни өчен дигәндә, ул кечкенәдән яхшы укыган. БДИ күрсәткечләре дә яхшы. Рус теленнән – 81, математикадан – 72 балл. Менә шулай укуда гамең булса, нәтиҗә дип бәргәләнәсе дә түгел.

Республика укучылары инде икенче ел информатика сынавын компьютерда тапшыра.

– Техник җиһазлар җитә. Анда бала үзе укыган мәктәптәге программа куелган. Өстәлдә – белешмә, әмма компьютерда интернетка чыгу мөмкинлеге юк. Ел дәвамында яңартылган стандартлар буенча эш алып барылды. Барысы да яхшы булыр дип уйлыйм, – диде Илсур Һадиуллин, информатика сынавы турында.

Министр белгы сынау нәтиҗәләреннән канәгать. «Нәтиҗәләр ил күләмендәге уртача күрсәткечләрдән югарырак. Алайса, ни өчен баллар былтыргыга караганда кимрәк? Андый сорау да туарга мөмкин. Без икенче ел дәүләт имтиханнарын яңартылган федераль стандартлар нигезендә тапшырабыз. Анда практик биремнәргә игътибар күбрәк бирелгән. Әлбәттә, балаларга җиңел түгел. Бу – бөтен Россия күләмендә шулай. Борчылырлык сәбәп юк, – дип, министр журналистларны быелгы нәтиҗәләр белән таныштырды. – Башка төбәкләрдәге күрсәткечләр белән чагыштырмыйбыз, бу – хата. Районнар арасында да рейтинглар үткәрмибез».

Татарстанда 158 укучы БДИда 100 балл туплаган. Араларыннан икесе математика һәм рус теленнән барлык сорауларга дөрес җавап биргән. 200әр балл җыючылар – Түбән Каманың 10 нчы мәктәбеннән Полина Еланская һәм Чистайдагы 1 нче мәктәпне тәмамлаган Александра Гришанова.

Химия, рус теле, география, математика фәннәреннән нәтиҗәләрне газетабызда хәбәр иткән идек инде. Физика, тарих, татар теле буенча да нәтиҗәләр ачыкланды. Әйтик, физиканы барлыгы 2094 укучы тапшырган, өч укучы 100 балл җыйган. Уртача күрсәткеч – 58,94. 68 укучы сынауда сынаткан (иң ким балл – 36). Тарихтан имтихан тотучылар – 1548. Уртача балл – 60,60. 88 укучы аны тапшыра алмаган. Татар теленнән бердәм республика сынавын 7 укучы сайлаган. Алар арасында 100 балл туплаучы юк. Күрсәткечләр – 80 балл тирәсе.

Имтиханның төп этабы 1 июльгә кадәр дәвам итәчәк әле. Алган билгеләреннән канәгать булмаучылар, җитди сәбәпләр аркасында сынауга килә алмаучылар, төп фәннәр – рус теле яки математикадан чик баллны үтә алмаучылар кабат белемнәрен сынап карый ала.

Сәрия МИФТАХОВА

22 июнь – Хәтер һәм кайгы көне

«ҖАЙСЫЗ» КОМАНДИРНЫҢ ХАК СҮЗЕ

1941 ел. Белоруссия чигендә борчулы көннәр өермәсе, шомлы хәлләр үзен гел сиздереп тора, әмма немецлар Советлар Союзына һөҗүм итәр дип беркем дә ышанырга җөрьәт итми.

Ул хаклы була

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының Альберт Борһанов җитәкчелегендәге Татар төбәкчеләре оешмасы үткәргән бөтенроссия конференциясендә беренче чиратта шушы тема күтәрелде. Моңа җирлек тә бар иде. Күптән түгел генә бер төркем галимнәр, төбәкне өйрәнүчеләр, журналистлардан торган Татарстан делегациясе, Белоруссиягә барып, Брест крепостенда да булып кайтты. Альберт Борһановка «Брест крепосте» мемориал комплексы директоры Григорий Бысюк белән дә сөйләшергә мөмкинлек туа. Аңлашыла ки, конференциядә әлеге темага кагылышлы сүз, ялгызы гына калгач та, аңын җуеп егылганчы крепостьны яклаучы якташыбыз, Советлар Союзы Герое Петр Гаврилов тирәсендә барды.

Милләттәшебез, керәшен егете Петр Гаврилов – Питрәч районы Әлбәдән авылыннан. Ул, 1939 елда Фрунзе исемендәге хәрби училищены тәмамлап, фин сугышында катнаша. 1941дә Брест крепостена билгеләнә һәм хезмәт урынына хатыны, улы белән килә. Гаврилов бу борчулы көннәрдә үзенең фикерен ачыктан-ачык әйтүче бердәнбер кеше була. Сугышның теләсә кайсы мизгелдә башланырга мөмкинлеген, моңа әзер булырга кирәклеген берничә тапкыр кабатлый. Ахыр чиктә аны фетнә оештыруда гаеплиләр. Бу «җайсыз» командирның эшен карарга дип, 27 июнь көненә утырыш билгеләнә. Ә 22сендә иртәнге 4 сәгать 15 минутта немецлар крепостька көчле артиллерия уты ачалар. Мондый хәлне берәү дә көтми, гарнизон бермәлгә каушап кала. Бу катлаулы вазгыятьтә Гаврилов командалыкны үз кулына ала. Беренче чиратта бар көчен кинәт кенә куркуга төшкән, паникага бирелгән кешеләрне тынычландыруга юнәлтә. Теләгенә ирешә. Гарнизон дошманның беренче һөҗүмнәрен кире кайтара. Мондый каршылык инде ярты Европаны яулап алган немецлар өчен көтелмәгән хәл була. Алар, сусаткыргычне җимереп, крепостьны сусыз, элемтәсез калдыралар. Крепостьтагы халык «таш капчык»та кала. Тәҗрибәле командирлар хатын-кызларны, балаларны, солдатларны чыгару юлын эзлиләр.

Питрәч районы егете Миңнур Шәмсетдинов якташы Петр Гаврилов эзләрен барлый.

Таш та «елый»

Крепостьны ялкын камап ала. Стеналар соңгы чиккә кадәр кыза. Чөнки крепостьны төзегәндә кулланылган кирпечләргә, нык булсын өчен, кургаш кушылган була. Бертуктаусыз яуган дошман утыннан алар эри башлый һәм күз яшьләре аккан кебек хис калдыра. Ташлар немецлар басымына түзә алмаса да, кешеләр крепостьта оборона тотуны дәвам иттерәләр. Дошманнарга каршы торуның соңгы урыны Петр Гаврилов җитәкләгән Көнчыгыш форт була. 30 июнь көнне анда «Сатана» дип исемләнгән ике тонна диярлек авырлыктагы авиабомба ташлыйлар. Бу шартлаудан җир ыңгыраша, корал саклана торган склад шартлый. Фортны саклаучылар саңгырауланалар, контузия алалар. Немец гаскәрләре форт территориясенә бәреп керә. Бу тарих битләрендә Брест крепостенда каршылык күрсәтүнең соңгы көне дип санала. Әмма Гаврилов һәм аның берничә сугышчысы бер ай диярлек көрәшә әле. Ахыр чиктә ул берүзе кала. Ачлыктан һәм контузиядән аңын югалткач кына, 1941нең 23 июлендә әсирлеккә эләгә.

Ялгызы гына крепостьны саклаган кешене күрергә дип, Гаврилов янына хәтта немец генералы килә. Совет офицерының батырлыгына хөрмәт йөзеннән, аны госпитальгә җибәрергә куша. Архив документларыннан күренгәнчә, ул бик авыр хәлдә, авырлыгы 40 килога калган була. Аңына килгәч, үз фамилиясен яшерүне кирәк дип таба, лейтенант Галкин булып йөри башлый.

«Халык дошманы» герой була

Петр Гавриловны 1945 елның маенда совет гаскәрләре азат итә. Әсирлектә булган һәр кешене тикшергән кебек үк аны да, бик җентекләп, НКВД тикшерә. Бәхет елмая: атып та үтермиләр, лагерьга да җибәрмиләр. Ә 1945нең көзендә Себердәге япон әсирләре яшәгән лагерьга начальник итеп билгелиләр. Хезмәтен тутыргач, ул туган авылына кайта. Әмма Әлбәдәндә дә, Питрәчтә дә эш таба алмый, чөнки әсирлектә булу сәбәпле, аны сатлыкҗан, «халык дошманы» дип кабул итәләр. Шулай итеп, сугышка кадәр бергә хезмәт иткән дуслары янына Краснодарга китеп бара. Анда сак хезмәтенә эшкә урнаша, йорт төзи.

1957 елда Сергей Смирновның «Брест крепосте» дигән китабы дөнья күрә. Бу вакыйга Петр Гавриловның язмышына бик зур йогынты ясый. Аны яңадан партия сафына алалар һәм Советлар Союзы Герое исеме бирәләр. 1958 елны СССР Югары Советына депутат итеп сайлана.

Герой Краснодарда яши, әмма Татарстанга еш кайта. Ул якташларына үпкә тотмый. Ветераннар белән рәхәтләнеп аралаша. Мәктәпләрдә чыгыш ясый.

Петр Гаврилов 1979 елның 26 гыйнварында Краснодарда вафат була. Ул үзен Брест крепостенда җирләргә васыять әйтеп калдыра.

Татарстан делегациясе геройның каберен зиярәт кыла, чәчәк куя. Питрәч районы Чыты авылы мәдәният йорты директоры Миңнур Шәмсетдинов якташының каберенә туган авылы Әлбәдәннән алып килгән бер уч туфрак сала. Ул күмелгән җирдән дә, туган җиренә алып кайту өчен, туфрак ала.

– Авылда митинг оештырып, бу туфракны Белоруссия җирендә һәлак булган авылдашларымның балалары, оныклары, туганнары катнашында аларның әниләре, хәләл җефетләре күмелгән каберләргә салдык. Ничә еллар үтсә дә, якыннарының ничек һәлак булуы, алар җирләнгән урыннар турында белү бик мөһим булып чыкты, – дип, уй-хисләре белән уртаклашты Миңнур.

Туган җирендә якташларын онытмыйлар. Быел Питрәч районында бишенче тапкыр бөтенроссия «Әлбәдән» хәрби реконструкция фестивале узачак. Быел программа тагын да киңрәк. Петр Гавриловның беренче тапкыр сугышка керүе тасвирланачак. Фашистларның, иртәнге дүрттә Буг елгасын кичеп, Совет җиренә үтеп керү вакыйгасы торгызылачак. «Брест крепосте легендалары» дигән күренеш тә булачак.

Мондый чаралар уйланырга мәҗбүр итә. Миңнур Шәмсетдинов та шундый фикердә.

– Фестивальдә ел саен 10–15 мең кеше катнаша, һәркем, тетрәнеп, елап, «тарих», «туган җир» дигән төшенчәләр турында уйланып кайтып китә, – ди ул.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

«Мин әтине күрдем...»

Беркөн әни караватта яткан җиреннән сискәнеп торып утырды. Күзләре зур булып ачылган, йөзе ниндидер гадәттән тыш сүз әйтәсе кешенеке кебек, борчулы да, тынгысыз да...

– Кызым... мин әтине күрдем!.. – ди ул, тыны кабып. Соңгы вакытларда нык авыргач, башта яшен тизлегендә әллә нинди уйлар үтеп китте. Күзенә күрендеме, саташамы икән... Минем сорау биргәнне көтеп тормыйча, үзе дәвам итте.

– Төштә күрдем, кызым. Сугышка киткәннән бирле бер тапкыр да күргәнем юк иде. Нәкъ шул вакыты. Бер нәрсә дә әйтмәде. Күренде дә уянып та киттем... Йокламаган да кебек идем, күрәсең, черем итеп алганмын.

Әнине инде хатирәләр өермәсе биләп алган иде. Аңа сорау бирәсе дә, сүз әйтәсе дә юк. Өтеренә кадәр инде үзем дә яттан белгән истәлекләрне ул мең дә беренче тапкыр, бер генә мизгелен дә үзгәртмичә, кабат сөйли башлады. Үзем аны тыңлыйм, үзем ул сөйләгәннәрне бүгенге хәлләр белән чагыштыра барам. 80 елдан соң ул кичергәннәрне кичерүчеләр, башкача булса да, үз башыннан үткәрүчеләр күпме, мин әйтәм.

– Әти сугышка киткәндә, миңа алты яшь була. Таң белән юлга кузгалалар. Шуңа күрә безне, кечерәк балаларын, уятып тормый. Кызгана. Мин ул китүгә, уянып чыктым. Алар әле авыл башында иде. Гомерем буе, нигә шул чакта артларыннан чапмадым икән, җитешкән булыр идем, әтине соңгы тапкыр күреп, кочаклап калган булыр идем дип үкендем. Әти үзе дә үкенә. Хатларында ул бөтен балаларына да багышлап шигырьләр яза иде. Менә миңа багышланганнарның берсе:

«Мәһиҗиһан кызым, чәчләреңне
Ник тарамадым икән?
Киткән чакта йоклап калдың,
Ник уятмадым икән?»

Әти амбар мөдире, авыл советы рәисе булып эшли. Шул ук вакытта яшерен генә авылның мулласы да була. Кача-поса яшьләргә никах укый, исем куша, соңгы юлга озата. Шуларны әйтеп, аның өстеннән әләк язалар. Аны: «Бәдәр исемле кызны күмгәндә гүр садакасы өчен сарык алган», – дип, кулга алдылар. Ә Бәдәр апай исән була, олыгайганчы яшәде. Аның исәнлеген раслау өчен биш ай вакыт кирәк була. Әтинең гаебе расланмады, ул төрмәдән кайтты. Тик кайтып, озак та үтми, сугыш башланды. Дүрт бертуганын да сугышка алып киттеләр. Нәҗип исемле энесе читтә иде, сугышка китәр алдыннан, авылга кайтып, бер кич кунды. Әтигә бүләккә күлмәк алып кайткан иде. Әти нәрсәгәдер исән кайтасына ышанмаган: «Нәҗип биргән күлмәкне кияр көннәр булырмы?» – дип яза.

Ул башта Суслонгерга эләгә. Ачлыктан, авыр эштән озак газап чигә. «Сугышка киткәннәр бәхетле», – дип яза. Әни аның янына, җәяүләп, ашаулар алып, ике тапкыр барып кайтты. Өч-дүрт ай үткәч кенә әтине сугышка җибәрәләр. Ул Волхов фронтына эләгә. «Беренче сугышта ук командирым белән икебез генә исән калдык. Балалар бәхетенә исән калдым», – дип яза. 1943 елны безгә: «Гомәр Бәдертдинов хәбәрсез югалды», – дигән кара кәгазь килде. Бик авыр булса да, әле үлмәгәндер дип ышандык, кайтыр дип көттек. Сугыш бетеп, авылга ирләр кайта башлагач, тагын да читен булды. Хәерчелек, ачлык, толлык, ятимлек үзәккә үткән иде шул. Әни берчак түзмәде: «Үзең булмагач, бу хатларың миңа нәрсәгә», – дип, әтинең хатларын мичкә якты... Без әле күп еллар аны кайтмасмы дип көттек, үлгән дигән хәбәре килмәде бит («Хәтер китабы»ннан гына аның 1943 елның 9 августында һәлак булганын, Смоленск өлкәсендә җирләнгәнен белдек. Шул ук китапта бертуганы Нәҗип абый турында да: «1942 елның 26 февралендә һәлак булган, Смоленск өлкәсенең Демидов районы Титовщина (Лоцяри) авылында җирләнгән», – дип язылган. – **Г.Х.**).

...Әни сөйли, ә мин тугызынчы дистәсен тутырып килүче, инде ике дистәгә якын оныкчыклары булган әбинең, бер мизгел эчендә сабый балага әйләнеп, әтисен сагынуын, күзләрендәге сагыш, ятимлек ачысын күреп, шаклар катып тыңлыйм. Аның гына түгел, тулы бер буынның фаҗигасе бит бу! Менә шуңа күрә дә алар гомер буе: «Сугышлар була күрмәсен!» – дип, кат-кат кабатлаган, өзгәләнеп теләгән шул инде. Безнең буын да инде бу сүзләрнең бөтен мәгънәсен аңлады дип беләм. Без дә инде, башка теләкләргә өстәп: «Сугыш афәтләрен күрсәтмә!» – дип телибез...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Чишенә урман

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгында әйтүләренчә, ефәк күбәләге 2022 елда Азнакай, Аксубай, Әлки, Биләр, Минзәлә, Нурлат һәм Чирмешән урман хуҗалыкларында ачыклана. «Эшкәртү алдыннан үсентеләр тикшерелергә, кирәкле документлар төзелергә тиеш. Ел дәвамында урман корткычлары булган урыннарда тикшерү үткәрелде, аларга каршы көрәш чаралары эшләнде һәм Урман федераль хуҗалыгы агентлыгына җибәрелде. Нәтиҗәдә 2023 елның май аенда Азнакай, Аксубай, Әлки, Биләр, Минзәлә, Нурлат һәм Чирмешән урманчылыкларында агачлар эшкәртелде. Бу эшләр Татарстан Республикасының Азнакай, Аксубай, Актаныш, Алексеевск, Әлки, Минзәлә, Мөслим, Яңа Чишмә, Нурлат, Сарман, Чирмешән һәм Чистай районнары чикләрендә дә башкарылды», – дип аңлаттылар матбугат хезмәтендә.

Урман корткычларына каршы чаралар барлыгы 53 мең гектар мәйданда үткәрелгән. Агачларны биологик «Дефилигнум» препараты ярдәмендә җир өсте ысулы белән эшкәрткәннәр. Әлеге препарат куркынычлыгы буенча өченче, дүртенче классларга карый. Белгечләр әйтүенчә, зыяны зур түгел. Хәзерге вакытта Татарстанда шушы чараларның нәтиҗәлелеге бәяләнә.

«Ефәк күбәләгенә каршы көрәш буенча барлык кирәкле чаралар күрелә», – диделәр министрлыкта. Белгечләр фикеренчә, урман корткычлары күрше төбәкләрдән күчкән. Аларның үрчүенә кышның чагыштырмача җылы килүе, язгы чорда һава торышының дымлы булуы, корткычлар белән тукланучы бөҗәкләрнең кимүе дә сәбәпче булырга мөмкин. Парсыз ефәк күбәләге кортлары агачның яфракларын ашап бетерсә дә, мондый агач шул ук елда яңадан яфрак яра ала.

Биектау районында исә каен агачларын корт баскан. «Ел коры килгәнгә, агачлар бетләде. Анысына гына түзәрлек, – ди Биектау урманчылыгы җитәкчесе Марс Мусин. – Шөкер, бездә ефәк корты юк. Салкыннар ярдәм иттеме, билгесез. Шулай да кул кушырып утырмыйбыз, көн-төн күзәтеп йөрибез. Быел урманнар аеруча игътибар сорый».

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ИЛҺАМ ЧИШМӘСЕ – МИҢГӘР

Соклану

Күренекле эшмәкәр Җәүдәт Миңнәхмәтовның чакыруы, Татарстан Язучылар берлегенең хәер-фатихасы белән язучылар Миңгәр ял һәм сәламәтлек комплексында ун көнлек иҗат командировкасында булып кайттылар.

Язучылар төбәкнең иҗтимагый-мәдәни тормышында да актив катнашты: төркемнәргә бүленеп, якын-тирә мәктәпләрдә укучылар, педагогия коллективлары белән очраштылар, район радио-телевидение тапшыруларында чыгыш ясадылар, Миңгәр авыл клубында концерт куйдылар, оешып килүче җирле музейны карадылар, комплексның локация объектлары һәм Саба дендрариенда экскурсиядә булдылар. Бу десант Берлек тарихында беренче мәртәбә оештырылды. Киләчәге дә өмет уята.

Мин – табигатьнең гүзәл бер бәллүендә, җырларда җырлана торган галибанә Агыйдел белән сөйкемле Сөн елгалары очрашкан төбәктә – Актаныш районының Кәзкәй авылында туып-үскән кеше. Аңлашыладыр, Кәзкәй – минем мәхәббәтем, илһам вә иҗат чыганагым. Әлбәттә инде, мондый урын башка була алмый!

Миңгәр туфрагына аяк басуга, мине иң беренче көнчелек хисе биләп алды. Ничек инде, ниндидер ерак кыр ягында Агыйдел – Сөн җәүһәрләре белән тиңләшерлек җир була алсын, ди?!

Икенче көнне, ашап-эчеп алгач, һәрвакыттагыча, тал агачыннан кулътаяк ясадым да сәфәр чыгып киттем. Иң әүвәл алдымда көзгедәй ялтырап, түгәрәк күл пәйда булды. Әйтерең бармы, матур, күркәм, саф-чиста, гүя рәссам әле генә ясаган да күргәзмәгә куйган.

Безнең як елга-күлләрендә, мисал өчен, аккошлар, акчарлаклар, үрдәкләр, ал тәпи фламинго, камыш аяк челәннәр, тагын әллә нинди көрәк томшыклы кошлар чыр-чу килә... Күл-елгаларга нәкъ менә шул кошлар җан өрә дә инде. Монда исә тавыш-тын сизелми, бакалар бардыр анысы, ә көндез аларның ял вакыты.

Озын сүзнең кыскасы, шушы ун көн дәвамында мин Миңгәр төбәге акваториясен аркылыга-буйга йөреп чыктым. Адым үлчәвечемнең угы әнә 88 чакрымны күрсәтә.

Шулай бервакыт мактауга искиткеч саран әдибебез Аяз Гыйләҗев белән җитди генә гәп корып утырабыз. Балта сораганда шөшле тоттыргандай, сүз сөрешен үзгәртеп:

– Марат, менә бу өстемдәге күлмәкне ничә көн кия дип уйлыйсың? – дип, каш астыннан гына миңа текәлеп бакты бу.

Җавап урынына җилкәләремне генә сикертеп куйдым. Ул һаман үзенекен куәтли: «Әйт әле, әйт», – ди.

– Ак күлмәк шәһәрдә бер көнлек инде, – дидем.

– Оп-пана, син дә Нәкыя сыңары, – дип, Аяз урыныннан торып басты, – беләсең килсә, өч көн киям инде мин аны, ә якасына кер төшмәгән. Бу бит, парень, Казаныбыз күзгә күренеп чистара дигән сүз.

Миңгәрдәге тәүге ачышым да чисталык-пакьлеккә мөнәсәбәтле. Кая гына барма, ешкынлыкларның кайсына гына кермә, таш-тауларның кайсына гына үрмәләмә, һәрберсе килен төшергән йорттай балкып тора.

Габделбәр Ризванов

Язучылар Миңгәрне үз итте. Авылның табигате, чиста һавасы, чишмәләренең суы язучыларыбыз күңеленә дәрт, илһам өстәде. Каләм әһелләре белән очрашуга Саба районы хакимияте башлыгы Рәис Миңнеханов та килгән иде. Җәүдәт Миңнәхмәтов очрашуларның дәвамлы булачагына ышандырды.

Иң җете модницалар подиумнарда гына кия торган кадак үкчәле туфлиләрен киеп, әлеге чакрымнарга сузылган сукмаклар буйлап һич шикләнмичә йөри алалар – тузан кунмаячак.

Янә дә шунысы хак: Агыйдел буе табигате – табигатьнең үзеннән. Миңгәр табигате исә – кеше тудырган табигать. Тирәнтен уйланылган, бөртекләп җыелган, яшәешкә, тормыш итүгә җайлаштырылган табигать. Шуның белән отышлырак та.

Күпләр Миңгәрне Татарстан Швейцариясе дип атый. Мәшһүр Альп таулары әлеге илне бизидер, билгеле, анда булганым юк, белмим. Шәхсән мин кайчандыр үзем иңләгән шундый ук таулы-кыялы Югославиягә тартым, дип фаразлар идем. Тик фараз ул әле чынбарлык дигән сүз түгел. Ленин бабай да әнә, һәр чагыштыру аксый, дип кисәтә. Швейцария чагыштыруы да – тапталып-изелеп, дөнья масштабында тешкә сыланган чагыштыру.

Миңгәр Швейцария дә, Югославия дә түгел. Монда күкнең җиденче катындагы риваяти Сидратүл – Мөнтәһә агачы астыннан юл алган ярсу инешләр кебек тау иңлекләреннән адым саен диярлек илаһи саф сулы татлы чишмәләр ургыла. Миңгәр ул сулы-чишмәле, таулы-урманлы, аюлы-бүреле, еланлы-боланлы, елгалы-күлле, җиләкле-җимешле, игенле-ашлы, мәчетле-манаралы...

Бәгъзеләрнең язучылар бушка ашап-эчеп, ял итеп кенә йөргәннәр икән дигән дәгъва белдерүе дә ихтимал. Урынсызга борчылмагыз. Рифә Рахман әнә шушы ун көн эчендә 16 шигырь язды. Миңзифа Әхмәтшина шигырен композитор Наилә Яхина көйгә салды. Халык алдында үзләре үк «на бис» башкардылар да. Тамашачылар Хәбир Ибраһим, Газинур Морат, Рәдиф Сәгъдинең (баянчы аккомпаниатор да) җырларын да алкышларга күмделәр.

Үзем исә илһамымны башыма гына сыйдырып бардым, бер җөмлә дә терки алмадым. Нишләмәк кирәк, иҗат ул – бик үзенчәлекле алгарыш. Җөмләдән, мин әдәби әсәрләрне үз фатирымда, үз урындыгыма утырып, үз өстәлемә таянып кына яза алам.

Бу язмама башта «Аккошлар, Миңгәр сезне көтә» дигән исем куймакчы идем. Китәргә бер көн кала күлләрнең берсендә нәни бәбкәләрен ияртеп йөзгән сылудан-сылу самими ана үрдәкне күргәч, фикерем үзгәрде, җиңел сулап куйдым.

Әлеге күл инде – бу үрдәк бәбкәләренең үз туган җире. Алар кайда гына кышласа да, бала чыгарырга шушында әйләнеп кайтачак.

Хак, Миңгәр – иҗатчылар өчен илһам чишмәсе. Ышанычым зур, бу әкияти җиһанны аккошлар да үз итәр.

Марат ӘМИРХАНОВ

Язучы фикере

Кабул булмас теләк

Бу язманы өч төрле итеп башларга мөмкин, әмма ничек башласаң да, яратмаучылар табылачак. Шулай булырга тиеш. Дөреслекне бөтенесе дә ярата, тик дөресен әйткән кешене генә яратмыйлар. Дөресен әйтсәң, ятимлеккә якынаясың. Әй, булсын ла. Мин гомеремдә дә беркемгә дә ярарга теләмәдем.

Мин компьютер бүләк итүләрен теләдем.

Туксанынчы еллар уртасы иде бугай. Редакциягә компьютерлар алып кайттылар. Күп иде алар, ләкин бөтен кешегә дә җитәрлек түгел. Ушлырак журналистлар шундук бүлешеп алып бетерде, мин генә аңгыраеп калдым. Ул вакытта кирәк тә кебек түгел иде, каләм белән дә язып була ич. Тора-бара бераз көнләштерә башлады, хәтта күңелгә шик төште. Бөтен кеше компьютерда эшли, киләчәктә дөнья шуңа калыр инде, ә мине, заман яңалыгын кабул итәлмәгән бәндәне, ипләп кенә читкә этәрерләр: «Моңарчы кулыңнан килгәнчә эшләдең, булдырдың, рәхмәт. Тик, гафу ит, яңа шартларда синең ише наданнарның кирәге юк. Рәхмәт һәм гафу ит, кыскасы. Үзең аңлыйсың инде...» Мин моны аңлаячак идем. Аңламас өчен наданлык кына җитми, ахмак та булырга кирәк...

Компьютерда бик өйрәнәсем килсә дә, алырлык акча юк иде. Журналистның хезмәт хакы белән компьютер алып буламыни! Һәм мин бер мәлне, Ходайга ялварган кебек итеп, көрсенеп куйдым: «Их, берәрсе компьютер бүләк итсә икән!» Хәзер ахмаклык кебек тоелса да, ул дәвердә мондый теләк бөтенләй үк җирлексез тоелмый иде. Кучеш чоры бит ул. Байлар әле саранлык чигенә җитмәгән, җилдән килгән акчаларын җилле эшләр өчен дә җиңел генә бирә беләләр иде. Әллә күпме изге гамәлләр ул чорда әнә шундый яңа байлар, иганәчеләр кулы белән эшләнде. Мәчетләр салдылар, концертлар оештырдылар, кемнәрнеңдер китапларын чыгардылар... Миңа гына компьютер алып бирмәделәр. Теләгемне Алла да, бәндә дә ишетмәгәч, хәлле генә бер танышка әҗәткә кереп, «Кызыл таң» гәзите редакциясеннән эсписәйт ителгән бер «Макинтош» сатып алдым.

Сөенүләремне күрсәң! Бурычка керергә мәҗбүр итсә дә, минем өчен барыбер зур бүләк иде бу. Сатып алынган бүләк. Бик күп хикәяләр шул «Макинтош»та язылды. Повестьлар. Канатланып эшләдем инде, үземне яңа заман кешесе итеп тойдым. Шулай бәхетнең җиденче катында йөргәндә, технологияләр тагын алга сикерде дә мин аның койрык асты тирәсендәрәк калдым. Минеке кебек «Макинтош»лар бөтенләй кулланылмый башлады.

«Каләм белән язам, компьютерда язган әсәрләрнең җаны булмый», – дип әйтүчеләр бар. Моны дөреслек дип түгел, ә авторның тойгысы итеп кенә карарга кирәктер. Заманнан артта калуына аклану эзли, дип тә кимсетергә ярамый. Иҗат ул – зәвык эше, һәр автор үзенә уңайлы булганча эшли. Мин компьютерда... Компьютерда язарга өйрәнгәч, кулдан эшлисе килми ул. Ә минем идеяләр күп, яңа әсәрләр кайнап тора, аларны язу өчен миңа компьютер кирәк. Сатып алырга акча юк, журналистның зарплатасы белән... «Их, берәрсе бүләк итсен иде...» – дидем.

Сәбәбе юк түгел, алда – утыз гына яшьлек булса да, юбилей кичәсе. Зур сарайда уза. Язучыларга, гадәттә, ат бүләк итәләр иде ул заманда. Бер-икесенә, шуңа өстәп, компьютер да бирделәр. Өмет бит инде ул... Хәер... Өмет үк түгел инде, чаткысы гына, чаткысының чаткысы гына... Кешеләргә әйтмәдем бит инде, Ходай нефть-газ өлкәсендә эшләүчеләргәме, чиновникларгамы нәрсәдер өләшеп йөри иде бугай – ишетмәде. Язучы сүзен кем ишетсен инде... Утыз яшьлек язучы сүзен...

Хәер... Бәлки, Ходай ишеткәндер... Китап чыкты. Шуның гонорарын алу белән туп-туры компьютерлар сатыла торган кибеткә киттем. Иң яңасын, иң яхшысын алдым. Аз гына бурычка керергә туры килде килүен... «Еллар буе язган китабың өчен тигән гонорар бер компьютер алырга да җитмәсен инде», – дип көрсенеп куйдым куюын. Аның каравы гаилә бюджетына артык зыян килмәде. Ә балаларга кирәк-яракны соңрак та алып була. Иң мөһиме, баш исән булсын да компьютер эшләп торсын.

Шулай дәртләнеп эшләп йөргән көннәрнең берсендә теге компьютер янып чыкты. Осталарның берсе дә төзәтә алмады. Процессорын алыштырырга туры килде. Тик андагы язмаларны гына коткара алмадык. Күп иде алар. Ни өчендер мин нәкъ әнә шул әсәрләрне, аларны язган чакларымны сагынам. Иң әйбәтләре шулар булгандыр кебек тә тоела. Алай түгелдер инде ул.

Их, берәрсе компьютер бүләк итсен иде...

Бу сүзне мин шул рәвешле тормышымның әллә күпме борылышларында әллә ничә тапкыр кабатладым. Бүләк бирүчеләр булмый тормады инде, тик шуларның барысын да кире җыеп алсыннар да компьютер бирсеннәр иде. Ул миннән беркайчан да артмаячак иде.

Әллә ничә компьютер тезелеп утыра хәзер. Эшләргә генә кирәк. Ә эшлисе килми. Яшьлектәге кебек ялкын да юк, дәрт тә юк. Минем генә түгел, әдәбиятның да кирәге шул чама гына бугай инде хәзер. Әдәбият кына түгел, татар үзе дә... Дәүләткә – татар, татарга татарлык кирәкми бугай. Их, берәрсе бүләк итсен иде, дип тә өзгәләнмим.

Шундый теләк белән яшәгән чорны сагынам гына... Их, шул чакларны берәрсе кире кайтарсын иде...

Марат КӘБИРОВ

ОСТАЗЫБЫЗ ИДЕ

Ветеран укытучыбыз, остазыбыз **Җәвидә Зиннәт кызы АЛИЕВА** 91 яшендә бакыйлыкка күчте. Ул баштарак Казан шәһәренең 10 нчы интернат-мәктәбендә, соңрак интернат-мәктәп 2 нче гимназия итеп үзгәртелгәч, балаларга математикадан белем бирде. Җәвидә апа тормышта авырлыкларга дучар булган балаларны да аналарча кайгыртты. Мөгаллимәбез «Мәгариф отличнигы» билгесенә дә лаек булды. Ул тормышка өмет белән караучы иде, балаларда да шундый сыйфат тәрбияләде. Дөнья классиклары әсәрләрен дә, халкыбыз әйтмешли, су урынына эчте.

Яшәеше эчтәлекле, сокланырлык, һәркайсыбызга үрнәк булды. Мөхтәрәм укытучы апабыз күңелләребездә мәңге сакланыр. Андый шәхесләр һич онытылмый, онытылмас та.

Камәрия ХӘМИДУЛЛИНА

МОҢНАР КАЙТА АВЫЛГА

Уйнагыз, гармуннар!

Актаныш гармунчылары кулларына янә тальян алган. Аеш авылыннан «Авыллардан – гармуннарга, гармуннардан – күңелләргә» проектын башлап җибәргәннәр. Узган ел 22 авылны әйләнеп, урамнарны моңга күмгән алар. Гармунчыларны балалар да, олылар да көтеп ала.

aktanysh-rt.ru

Актаныш районының Иске Сәфәр мәдәният йорты мөдире Илдус Һарунов әйтүенчә, әлеге чара республиканың башка бер районында да үтми. Бу проект – клубта оешкан «Баламишкин егетләре» ансамбле идеясе. Анда Балтач, Зөбәер, Түке, Урьяды, Богады, Сәфәр, Байсар, Гәрәй авылларыннан унлап егет җыела. Арада 25–30 ел эшләгән мәдәният хезмәткәрләре бар. Бергәләп яшен-картын җырлата, биетәләр. 80–90 яшьлек әбиләр, аяклары авыртса да, тыпырдашып утыра. Зөбәердә 93 яшьлек әбиләргә кадәр дөбердәтеп биегән. «Их, минем әти, гармун уйнап, сугышка чыгып киткән иде бит», – дип, күз яшьләрен сөртүчеләр дә булган.

– Халык гармун көйләренә сусаган. Бу чараны өченче ел үткәрәбез. Максатыбыз – авылларга чыгып, гармун моңнарын кайтару, баянчыларның абруен күтәрү. Әлеге егетләр үз авылларында бәби туеннан башлап туй, туган көн, армиягә озату, каршы алу кебек төрле мәҗлесләрдә катнаша. Аларны үз авылларында болай да беләләр, башкаларга да күрсәтәсебез килде. Алмаш турында да уйлыйбыз. Йөз баланың берничәсе генә гармунга тартылса да, бик яхшы бит, – ди җор телле Илдус Һарунов.

Гармунчыларның алтмышар чакрым үтеп килгәннәре бар. Эштән соң арыдым дип тору юк. Кичке сәгать 6да чыгып китеп, төнлә генә өйләренә кайталар. Башта урам буйлап йөриләр, аннан клуб янында концерт куялар. Менә шундый җырлы-моңлы тамаша, кыскасы. Иң беренчесен Чишмәбаш авылыннан башлаганнар икән. Башта үзләре дә, халык килерме икән, дип борчылган. Капка төбе саен җыелган халыкны, корылган табыннарны күргәч, күңелләренә җылы йөгергән. Кечкенә яки зур авыл дигән нәрсә юк. Кайда халык – шунда баралар.

Илдус Һаруновның үзенең гармун тарта башлавына – 40 ел. Әтисе Һади баянчы булган. Озынайтылган көн төркеменә йөргәндә, укытучы Әнисә апасы гармун алып килергә кушкан. Барысы да менә шуннан башланган. Каникулда тырыша-тырыша өйрәнгән.

– Әгәр берәү урамда гармун күтәреп, җырлап йөрсә, авылда, әһә, бу салмыш бугай, диячәкләр. Менә шундый заманга килеп җиттек. «Баламишкин егетләре» шушы калыпны җимерде. Безне бар җирдә сагынып көтеп алалар, –ди 52 яшьлек Илдус әфәнде.

Башка елларны Иске Байсар авыл җирлегенә дә барганнар. Быел да көтәләр аларны.

– Әлбәттә, күңелле чара. Яшь буынга традицияләрне җиткерү бит бу. Гармунчыларыбыз бар әле, Аллага шөкер. Сабан туен үзебезнең үзешчәннәр башлап җибәрде. Халык тальян көйләрен бик ярата. Читтән килгән гармунчылар ничек уйный икән дип, игътибар белән күзәтә, – ди Иске Байсар авыл җирлеге башлыгы Рәмис Кадыйров.

Иске Айман авылы клуб мөдире Кадрия Сәетованың да фикерен сораштык.

– Бу проектны халык бик уңай бәяли. Үзем дә ел саен катнашам. Җирлектә «Баламишкин»нарга кушылырлык гармунчылар юк анысы. Авыллар картая бара. Сабан туйларына кыйммәтле артистларны чакыралар. Халыкка башта гына кызык иде. Хәзер алар кирәкми. Нәкъ менә гармунчылар катнашындагы чаралар тансык. Үзләре дә рәхәтләнеп бииләр, җырлыйлар. Быел да көтеп калабыз, – ди Кадрия Сәетова.

Егетләр остарып беткән инде, урамнарда гына йөрми, шәһәр сәхнәләренә дә менеп уйныйлар. «Уйнагыз, гармуннар!»да өч ел рәттән лауреат булганнар. Удмуртия, Башкортстан республикаларына да чыгалар. Быел барлыгы 17 концерт оештырганнар. «Баламишкин»нар хәрби операциядә катнашучыларга хәйрия концерты да куйган. Җырлап, 300 мең сумнан артык акча җыйганнар. Әлеге егетләрнең гаиләләренә, әти-әниләренә булышканнар. Менә шундый игелекле, халыкның кәефен бушка күтәрә белә торган гармунчылар яши Актанышта.

Сәрия МИФТАХОВА

2023 ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ
МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

БҮЛӘГЕҢ ӘЗЕРМЕ?

21 ҺӘМ 23 ИЮНЬДӘ КАЗАНДА САБАН ТУЕНА СӨЛГЕ ҖЫЯЧАКЛАР

Гореф-гадәт, йолалар

Чиратта – башкала. Бу атнада Казанда милли бәйрәмебез гөрләячәк. Ул нәрсәсе белән үзенчәлекле булыр? Башкала Сабан туена бүләк җыюда кемнәр катнашыр? Бу хакта матбугат очрашуында сөйләделәр.

Быел Казанда Сабан туе 24 июньдә Тынычлык, Дәрвишләр бистәләре һәм Аккош күлендә узачак. Моннан тыш, 23 июньдә Казан ипподромында ат чабышлары булачак. Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева быелгы бәйрәмнең кайбер үзенчәлекләре турында сөйләде.

– Быел без милли бәйрәмнәрне, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсе буенча, тарихи эчтәлегенә йөз тотып уздырабыз. Казан Сабан туена килгәндә, быел бәйрәмнең тантаналы өлешендә дә, төрле остаханәләр, уеннарда да традицион милли үзенчәлекләргә игътибар зур булачак. Әйтик, барыбызның да Сабан туенда уздырыла торган уеннарда катнашканыбыз бар, әмма аларның кайдан һәм ни өчен килеп чыкканын белмибез. Милли ашларыбыз белән дә шулай ук. Казанда узачак бәйрәмдә менә шуларга игътибар биреләчәк. Аннан соң, бәйрәмнең аһәңе ниндидер техник чараларга гына кайтып калмасын иде. Шуңа да быел музыкаль бизәлешне халык уен кораллары баетачак, – диде ул.

Юл бирегез – атлар килә!

Сабан туена бүләкне 21 июньдә үк җыя башларга ниятлиләр. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы Азат Абзалов сүзләренчә, матур итеп бизәлгән җигүле атлар Залесный бистәсеннән «Салават Күпере» торак массивына таба һәм Дәрвишләр бистәсе буйлап та йөриячәк. «Һәркемгә бу күркәм, тарихи йолада катнашырга киңәш итәм», – диде ул.

Ә 23 июньдә бүләк җыючылар Казанның дүрт почмагыннан: Кремль, Ирек мәйданы, «Туган авылым» комплексы һәм Иске Татар бистәсеннән чыгып китәчәк. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов исеменнән дә бүләк тапшырырлар дип көтелә. Сез дә бер-бер нәрсә әзерләп куя аласыз. Иң мөһиме – исем-фамилиягезне языгыз. Шулай иткәндә, исемегезне Сабан туенда искә алачаклар.

– Сабан туена бүләк җыю – балачагымның җылы бер хатирәсе. Бәйрәм алдыннан һәр өй саен бүләк җыеп урам әйләнүләрен, 60 ел узса да, искә алам.

Фикер

Ләйлә ФАЗЛЫЕВА, Татарстан Премьер-министры урынбасары:
– Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы күп нәрсәләргә игътибар итәргә мөмкинлек бирде. Шул исәптән, милли кием мәсьәләсенә дә. Бүген аңа карата кызыксыну артты. Мин исә милли бәйрәмнәребезгә дә асылыбызны күрсәтә торган киемнән килергә тәкъдим итәм. Шул рәвешле балаларга, киләчәк буынга үрнәк күрсәтүебез турында онытмыйк. Бәйрәмгә барыр алдыннан балаларыбызга Сабан туеның асылын, тарихын сөйлик. Бу бәйрәмне ял итү, күңел ачу чарасы гына дип кабул итмәсәк иде. Сабан туенда катнашу – тарихи мирасны саклауга өлеш кертү дә әле ул.

Бу матур йоланы Казанда да уздырасы килде. Әлеге тәкъдимне җитәкчелегебез дә хуплады. Һәм менә инде бишенче тапкыр, атлар җигеп, җырлап-биеп, Казан урамнарын әйләнергә җыенабыз, – диде Татарстанның Рестораторлар берлеге рәисе Зөфәр Гаязов.

Җиде җигүле ат, җырлап-биеп алырга, бүләкләрне кабул итәргә туктыйтуктый, Камал театрына таба хәрәкәт итәчәк. Зөфәр Гаязов ышандырганча, атлар юлда тоткарлыклар тудырмаячак. 13.00 сәгатьтә исә барысы да җыелган бүләкләре белән Камал театры янында очрашачак. Анда бәйрәм театральләштерелгән тамаша белән дәвам итәчәк.

Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин фикеренчә, Сабан туена бүләк җыюның максаты – әлеге йоланы балаларга, үсмерләргә күрсәтү, аларны ияртү.

– Бу йола һәр авылда диярлек уздырыла. Ә Казан өчен ул – яңалык. Быел ул шундый зур масштабта беренче мәртәбә узачак. Иң мөһиме – теләгән һәркем Сабан туе батырларына атап үз бүләген тапшыра алачак, – дип сөйләде ул.

Урам тутырып җырлап, бүләк бирүчеләрне Казанның ташлы юллары кызганчы биетүгә Мәдәният институты җавап бирәчәк. «Студентларыбыз да, остазларыбыз да нык әзерләнә», – диде институт ректоры Роза Әхмәдиева. Ул шулай ук бу йоланың тарихына да тукталды.

– Сабан туена бүләк җыю – бәйрәмнең матур бер бизәге генә түгел. Элек-электән җыелган бүләкләрнең явыз көчләрдән саклап, тормышка уңыш китерү көченә ышанганнар. Бүләк җыйганда егетләр – көчен, кызлар уңганлыгын күрсәткән. Һәр кыз бала ел буе Сабан туена дип чигү чиккән бит элек, – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

«Татар-информ»

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5315 данә
Гомуми тираж – 14253 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 287

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+